ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» апреля 2021 ел №107

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданының исәп нормасы һәм торак урын мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган торак урыны гомуми мәйданының 18 кв. метрдан да ким булмаган күләмендә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.
2. Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданын бирү нормасын Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында бер гражданга торак урынның гомуми мәйданының 18 кв. метр күләмендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып билгеләргә.
3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын үзгәртү Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урын мәйданының исәпкә алу нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы турында» 2008 елның 29 декабрендәге 680 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**